| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЛАРЫ |
|---|---|---|

**КАРАР** **КАРАР**

**10.02.2020** Кукмара шәһәре **№ 142**

«2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында мәгарифне үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 14 мартындагы 183 номерлы карары белән расланган «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында мәгарифне үстерү» муниципаль программасын әлеге карарның кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 10.02.2020 елның 142 номерлы карарына кушымта

# «2018-2020 елларга КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ» МУНИЦИПАЛЬ МАКСАТЧАН ПРОГРАММАСЫ

(алга таба – Программа)

## I. ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2018-2020 елларга Кукмара муниципаль районында мәгарифне үстерү» муниципаль программасы |
| Программаның максаты | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә төбәк икътисадының инновацион үсеше ихтыяҗларына, җәмгыять һәм һәр гражданинның өметләренә җавап бирә торган сыйфатлы белем алу мөмкинлеген тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | 1. Белем бирүнең эчтәлеген һәм технологияләрен камилләштерү, мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү системасында барлык категория балалар өчен, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен сыйфатлы белем алуда тигез мөмкинлекләр булдыру.<br>2. Муниципаль гомуми белем бирү системасының икътисадның инновацион үсеше таләпләренә туры килүен, җәмгыять һәм һәр гражданның өметләрен канәгатьләндерүен тәэмин итә торган шартлар тудыру, тәрбия һәм гомуми белем бирү системасында заманча сыйфатлы белем бирү һәм балаларны уңай социальләштерү өчен тигез мөмкинлекләр тудыру.<br>3. Белем бирү сыйфатын күтәрү максатларында белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан карарлар кабул итү процессларын ышанычлы һәм актуаль мәгълүмат белән тәэмин итү.<br>4. Сыйфатлы белем алуны тәэмин итә торган инфраструктураны һәм оештыру-икътисадый механизмнарны үстерү.<br>5. Мәктәп яшендәге балалары булган Кукмара муниципаль районы территориясендә яшәүче гаиләләргә гомуми белем бирүнең уңайлы сыйфатлы хезмәтләрен тәэмин итү һәм ерак территорияләрдә авыл җирендә яшәүче кече мәктәп яшендәге балаларга заманча таләпләргә туры килә торган сыйфатлы белем алуга хокук бирү. |

| | |
|---|---|
| | 6. Һәркем өчен мөмкин булган мәктәптә белем алуга гражданнарның хокукларына дәүләт гарантияләрен тәэмин итү. |
| Ярдәмче программалар исемлеге | 1. «2018-2020 елларга мәктәпкәчә белем бирүне үстерү» ярдәмче программасы<br>«2018 – 2020 елларга гомуми белем бирүне үстерү» ярдәмче программасы<br>«2018-2020 елларга өстәмә белем бирүне үстерү» ярдәмче программасы<br>«2018-2020 елларга белем бирү сыйфатын бәяләү системасын үстерү» ярдәмче программасы |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2018-2020 еллар.<br>Программа бер этапта тормышка ашырыла |
| Программаны финанс белән тәэмин итү | Программаны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслауның гомуми күләме 2700630,8 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча да:<br>2018 год – 925795,9 мең сум<br>2019 год – 913651,3 мең сум<br>2020 год – 861183,6 мең сум<br><br>Искәрмә: Программаны финанслау күләмнәре фаразланган характерга ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш. |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | Максатка ирешү индикаторлары:<br>- иң яхшы БДИ нәтиҗәле 10% белем бирү учреждениесендә бердәм дәүләт имтиханнарының уртача баллының (1 предметка исәпләгәндә) иң начар БДИ нәтиҗәле 10% белем бирү учреждениесендәге бердәм дәүләт имтиханнарының уртача баллына (1 предметка исәпләгәндә) карата нисбәте 1,46 га кадәр кимиячәк;<br>6,5-18 яшьләрдәге халыкның гомуми исәбендә 6,5-18 яшьләрдәге белем бирүгә җәлеп ителгән халыкның чагыштырма саны 99,2 % ка кадәр артачак;<br>Гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның гомуми исәбендә төрле дәрәҗәдәге олимпиадаларда катнашучы гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның чагыштырма саны 70% дәрәҗәсендә саклананачак;<br>- укучыларның гомуми исәбендә төп заманча таләпләр |

| | |
|---|---|
| | нигезендә белем алу мөмкинлеге бирелгән муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучыларның чагыштырма саны 81,5% ка кадәр артачак;<br>- Белем бирү учреждениеләренең гомуми исәбендә инвалидларны һәм үсештә кимчелекләре булмаган затларны бергә укытуны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган универсаль каршылыксыз мохит булдырылган белем бирү учреждениеләрнең өлеше 20% дәрәҗәсендә саклаunion;<br>- ннвалид-балаларның гомуми исәбендә белем алу хезмәтләрен дистанцион укыту рәвешендә алучы инвалид-балалар өлеше 40% дәрәҗәсендә саклаnачак;<br>- белем бирү оешмаларының гомуми исәбендә җәмәгатьчелек катнашында коллегиаль идарә органнары (ата-аналар, эш бирүчеләр) төзелгән мәгариф оешмаларының чагыштырма саны 100% ка кадәр артачак;<br>- белем бирү оешмаларының гомуми исәбендә рәсми сайтларда үз эшчәнлекләре турында норматив беркетелгән белешмәләр исемлеген бирүне тәэмин итүче белем бирү оешмаларының агыштырма саны 100% ка кадәр артачак;<br>- белем бирү, өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләренең гомуми исәбендә соңгы өч ел эчендә квалификацияне күтәрү яисә һөнәри яктан яңадан әзерлек узган муниципаль белем бирү учреждениеләре һәм өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләренең чагыштырма саны 98% ка кадәр артачак;<br>Аттестацияләнгән педагогик хезмәткәрләрнең гомуми исәбендә югары квалификацияле педагогик хезмәткәрләр өлеше 22% ка кадәр артачак;<br>Аттестацияләнергә тиешле җитәкче һәм педагогик хезмәткәрләрнең гомуми санында аттестацияләнгән җитәкче һәм педагогик хезмәткәрләр өлеше 98,5 % ка кадәр артачак;<br>- Программа кысаларында эшләнгән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә (алга таба – Интернет челтәре) керү мөмкинлеге бирелгән электрон инструктив-методик ресурсларның программа кысаларында эшләнгән электрон инструктив-методик ресурсларның гомуми санында тоткан урыны 100% тәшкил итә.<br><br>Турыдан-туры нәтиҗәләр күрсәткечләре:<br>- төрле дәрәҗәдәге олимпиадаларда һәм конкурсларда |

| | |
|---|---|
| | катнашучы гомуми белем бирү программалары буенча укучылар саны ел саен 1050 кеше дәрәҗәсендә саклана;<br>- балаларга гомуми белем һәм тәрбия бирү системасында ел саен 60 район чарасын үткәрү;<br>- белем бирү сыйфатын тышкы бәяләү механизмнары гамәлгә ашырыла торган гомуми белем дәрәҗәләре саны 2 тапкырга артачак;<br>- Белем бирү учреждениесендә 35 яшькә (включительно) кадәрге укытучылар саны 25,5% ка кадәр артачак;<br>- киләсе өч елда квалификация күтәрү яисә һөнәри яктан яңадан әзерләү узган муниципаль мәгариф учреждениеләренең җитәкче һәм педагогик хезмәткәрләре саны муниципаль белем бирү учреждениеләренең җитәкчеләре һәм педагогик хезмәткәрләре санына карата 100% ка кадәр артачак;<br>- Программа нәтиҗәләрен тарату буенча район дәрәҗәсендә үткәрелгән чаралар саны ел саен 2 берәмлектән дә ким булмаячак. |
| Программаның җаваплы башкаручысы | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе |

### 2.1.1. Гомуми белем бирүнең агымдагы торышы характеристикасы

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәркем өчен мөмкин булган сыйфатлы гомуми белем бирүне үстерүгә аерым игътибар бирелде. Кукмара муниципаль районында 2013/2014 уку елының беренче сыйныф укучыларының 90 % ы – мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен тәмамлаучылар. Ел саен 1 нче сыйныфка укырга кергән әзерлексез балалар саны күрсәткече кими бара, әмма мәктәпкәчә белемнең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү һәм барлык балаларга мәктәпкә керү өчен тигез старт мөмкинлекләрен бирү максатыннан, әлеге яшьтәге балаларга мәктәпкәчә белем бирү процентын арттыру бурычы актуаль булып кала. Моның сәбәбе – мәктәпкәчә яшьтәге балаларның билгеле бер проценты мәктәпкәчә белем бирү оешмалары булмаган ерак урнашкан торак пунктларда яши.

Мәктәпкәчә белем алу мөмкинлегеннән тыш, аның сыйфаты мәктәпкәчә белем бирү системасы үсешенең төп бурычларыннан берсе булып тора. Әлеге мәсьәләне хәл итү мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең һөнәри квалификациясе дәрәҗәсенә, аларның методик әзерлегенә бәйле.

Гражданнарның бушлай башлангыч, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру максатыннан Кукмара муниципаль районында 2013-2014 нче елның 1 нче сентябренә 32 белем бирү учреждениесе эшли.

Районның гомуми белем бирү системасы белем бирү хезмәтләренең шактый киң спектрын тәкъдим итә торган гомуми белем бирүнең төрле

дәрәҗәдәге барлык төрләре белән тәкъдим ителгән.

Белем бирү учреждениеләрендә укыту, МБГББУ«Кукмара 3 номерлы мәктәбе»ннән тыш, бер сменада алып барыла. Профильле укыту районның барлык мәгариф учреждениеләрендә дә саклана. Профильле укыту программасында укучыларның 98% ы катнаша.

Районның белем бирү оешмаларының укыту-лаборатория базасын модернизацияләү соңгы елларда шактый динамик рәвештә гамәлгә ашырыла, шул исәптән «Мәгариф» өстенлекле илкүләм проекты һәм 2010-2015 елларга ТРда мәгарифне үстерү «Киләчәк» стратегиясе кысаларында да.

Гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү этаплап гамәлгә ашырыла.

Районның белем бирү оешмаларында гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында заманча уку җиһазлары белән тәэмин итү проблемасы саклана.

Яңа белем бирү стандартларына уңышлы күчү бары тик педагогик хезмәткәрләрнең һәм белем бирү оешмалары җитәкчеләренең уку процессын оештыруга карата яңа таләпләр контекстында квалификациясен күтәрү шарты белән генә мөмкин.

Районда гомуми белем бирү мәктәпләрендә бердәм белем бирү процессына кертелгән сәламәтлекләре буенча мөмкинлекләре чикләнгән балалар саны арту күзәтелә, 2012 елдан 67 кешедән 2013 елга 70 кә кадәр арта. Ел саен бу күрсәткеч уртача 4% ка арта.

Мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен белем бирү хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеген булдыру мәсьәләсен хәл итү өчен, өйдә укыту системасын үстерү буенча проект, шул исәптән дистанцион технологияләрне кулланып тормышка ашырыла. Хәзерге вакытта Кукмара районында дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып белем алуга медицина каршылыклары булмаган һәм шул ук уку формасы буенча укырга теләүче26 инвалид бала дистанцион белем ала, бу гомуми белем бирү программалары буенча өйдә индивидуаль белем алучы инвалид балалар санынннан 92 % тәшкил итә.

Сәләтле балаларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү буенча чаралар үткәрүдә уңай тәҗрибә тупланган. Олимпиадаларның республика һәм төбәк этапларында җиңүчеләр һәм призерлар саны – 34 укучы. Муниципаль этап җиңүчеләре һәм призерлары барлык урта гомуми белем бирү мәктәпләрендә дә бар. Сәләтле балаларның район электрон базасы уку елы дәвамында даими рәвештә тулыланып тора. Шул ук вакытта сәләтле укучылар белән эшләүдә кайбер проблемалар да бар:

- Мәгариф идарәсе сайты ресурсларыннан әлеге сорау буенча мәгълүмати ачыклык өчен җитәрлек дәрәҗәдә файдаланмау.

- интеллектуаль сәләтле укучыларның белем алуда ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен ресурслардан җитәрлек дәрәҗәдә файдаланмау;

- интеллектуаль һәм иҗади эшчәнлек белән кызыксынучы балалар белән дистанцион, читтән торып һәм көндезге-читтән торып эшләү рәвешләрен тиешенчә файдаланмау;

- интеллектуаль эшчәнлек белән кызыксынучы балалар өчен профильле лагерьларның мөмкинлекләрен җитәрлек дәрәҗәдә кулланмау.

## 2.1.2. Гомуми белем бирү сыйфатын бәяләү системасы

Соңгы елларда белем бирү сыйфатын бәяләүнең эчке системасы барлыкка килә, ул Кукмара муниципаль районы мәгариф системасының мөһим компоненты булырга тиеш. гомуми белем бирү сыйфатын бәяләүнең муниципаль системасы:

белем бирү сыйфатын эчке һәм тышкы бәяләү механизмнары;

муниципаль мониторинг тикшеренүләре.

Белем бирү сыйфатын бәяләү системасы үзәкләштерелгән тикшерүләргә һәм контрольгә генә түгел, ә бөтен мәгариф системасының һәм аерым оешмаларның ачыклыгына да таянырга тиеш. Белем бирүнең барлык дәрәҗәләрендә сыйфатны бәяләүнең төрле инструментларын һәм процедураларын кертү мәгариф системасы эшчәнлегенең мәгълүмати үтә күренмәлелеген күтәрү, унификацияләнгән сораулар нигезендә кире элемтә механизмнарын үстерү белән бергә алып барылырга тиеш.

Белем бирү сыйфаты белем бирү оешмалары эшчәнлегенең төп характеристикасына һәм кызыксынган якларның – гражданнар, җәмгыять, дәүләт – ихтыяҗларының ничек тормышка ашырылуы турында мәгълүмат чыганагына әверелә.

Сыйфатны бәяләүнең формаларын һәм эчтәлеген үстерү мәгариф системасы турында мәгълүматның үсүенә һәм, нәтиҗә буларак, идарә карарларын кабул итү өчен, бу мәгълүматны дөрес куллану проблемасының кискенләшүенә китерәчәк. Моның өчен муниципаль системада җыела торган мәгълүмат сыйфатын бәяләү нигезендә тикшеренүләргә һәм аналитикага яңа алымнар кирәк.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, гаилә һәм җирле җәмәгатьчелекне белем бирүгә җәлеп итү – аның эшчәнлеге һәм үсешенең мөһим ресурсы. Белем бирү оешмалары белән идарә итүдә иҗтимагый катнашу механизмнарын формалаштыруны тәэмин итәргә кирәк.

Белем бирү сыйфатын бәяләү һәм мәгариф системасының үтә күренмәлелеген үзгәртү системасында принципиаль үзгәрешләр түбәндәге юнәлешләрдә барачак:

белем бирү сыйфатын бәяләүнең заманча һәм балансланган, барыннан да элек, укучыларга белем бирү һәм социальләшүне мониторинглауны, белем бирү нәтиҗәләрен бәяләү процедураларын үз эченә алган муниципаль системасын формалаштыру;

белем бирүнең сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән төрле индивидуаль белем бирү казанышларын бәяләү һәм исәпкә алу инструментларын кертү;

белем бирү оешмалары дәрәҗәсендә белем бирү сыйфаты белән идарә итү өчен эчке бәяләүнең (үз-үзеңне тикшерү) үтә күренмәле процедураларын кертү;

җәмәгатьчелек һәм эш бирүчеләр катнашында белем бирү оешмаларының эш сыйфатын бәяләүнең тышкы бәйсез системасы механизмнарын гамәлгә кертү;

региональ дәрәҗәдә педагогик үлчәү һәм белем бирү сыйфатын бәяләү өлкәсендә кадрлар потенциалын үстерү;

шәхси белем бирү казанышлары, белем бирү оешмалары һәм системалары эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат җыю һәм анализлау системасын булдыру;

аналитик эшкәртү һәм җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү өчен белем бирү оешмалары турында мәгълүматлар җыюны тәэмин итү

Стратегик документларның төп ориентирлары нигезендә белем бирү сыйфатын бәяләү өлкәсендә өстенлекле бурычлар билгеләнде:

белем бирү сыйфатын бәяләү процедураларының төбәк дәрәҗәсендә гамәлгә ашырыла торган тулы һәм балансланган системасы нигезендә бердәм белем бирү киңлеген формалаштыру һәм үстерү;

белем бирү сыйфаты мониторингы системасын кертү;

белем бирү системасы, аерым оешмаларның эш сыйфаты турындагы мәгълүматның мөмкин булган кадәр үтә күренмәлелеген һәм үтемлелеген тәэмин итү;

тышкы кызыксынучы затларны һәм оешмаларны (иҗтимагый һәм һөнәри-иҗтимагый экспертларны һәм оешмаларны) белем бирү сыйфатын бәяләүгә җәлеп итү;

җәмәгатьчелек катнашында белем бирү оешмасының эш сыйфатын бәяләүнең бәйсез системасын булдыру, гавами рейтинглар, эшчәнлекләренә рейтинглар кертү.

### 2.1.3. Гомуми белем бирү системасы үсешен ресурслар белән тәэмин итү

2013/2014 уку елы башына Кукмара муниципаль районында 32 гомуми белем бирү учреждениесе эшли.

Кукмара муниципаль районының барлык белем бирү учреждениесенең белем бирү эшчәнлегенә хокук лицензияләре бар, аккредитация үтәргә тиешле учреждениеләр – аккредитацияләнде.

12% ы хәзерге вакытта автоматик янгын сигнализациясе һәм «хәвеф төймәләре» системалары белән җиһазландырылган.

Муниципаль бюджет акчалары хисабына райобелем бирү учреждениеләренең янгын куркынычсызлыгын көчәйтү буенча чаралар башкарылды: янгын сүндергечләр сатып алынды һәм перезаряжать ителде, электр үткәргеч изоляциясе каршылыгы үлчәүләре башкарылды, чардак түшәмәләрен уттан саклый торган эшкәртү башкарылды, автоматик янгын сигнализациясе системаларын монтажлау һәм хезмәт күрсәтү һәм янгын турында кешеләргә хәбәр итү һәм тузган электр үткәргечләрне өлешчә алыштыру буенча эшләр башкарылды, янгын сулыкларын төзү һәм ремонтлау буенча эшләр башкарылды, сулыш органнарын шәхси саклау чаралары сатып алынды, ишек притворларында уплотнительләр һәм ишекләрне үзлектән ябылу җайланмалары урнаштырылды, янгынга каршы ишекләр куелды, балаларны эвакуацияләү юлы янгынга каршы нормаларга туры китерелде.

Чаралар планын гамәлгә ашыру белем бирү учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге кайбер проблемаларны юкка чыгарырга,

янгын куркынычсызлыгы дәрәҗәсен арттырырга, белем бирү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытырга, янгын саны артуны туктатырга һәм алардаюгалтуларны киметергә, кешеләр күп була торган мәгариф учреждениеләрендә куркынычсыз шартлар булдырырга, аларның һәлак булуына юл куймаска мөмкинлек бирде.

Мәктәп автотранспортын яңарту гомуми белем бирүне модернизацияләү буенча чаралар комплексын тормышка ашыру кысаларында тормышка ашырыла. 2013 елда муниципаль белем бирү учреждениеләре өчен 2 автобус сатып алынды. Шулай итеп, ерак торак пунктлардан укучыларны база мәктәпләренә илтүне оештыру максатында 9 берәмлек мәктәп автобусы җәлеп ителде.

Шулай ук белем бирү учреждениеләрен яңа уку елына әзерләү эшенең бер юнәлеше – уку әдәбияты белән тәэмин итү.

Дәреслекләрне сатып алу дәреслекләрнең Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 2013/2014 уку елында белем бирү процессында файдалануга тәкъдим ителгән (кертелгән) Федераль исемлеге нигезендә башкарыла (исемлек РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 2012 елның 19 декабрендәге 1067 номерлы боерыгы белән расланган).

Ел саен уку әдәбияты белән тәэмин итүгә нәшриятлар белән контрактлар төзелә. 2013 елда уку әдәбиятын сатып алуга акча суммасы 150 мең сумга арткан (коррекция интернат-мәктәбе – 100 мең сум). 5465 данә дәреслекләр (17.10.13 елга мәгълүматлар буенча) сатып алынды (коррекция интернат-мәктәбе – 545 данә эш дәфтәрләре).

Белем бирү учреждениеләре мәгълүмати технологияләрне укыту барышында актив куллануларын дәвам итәләр. Районның барлык мәктәпләре дә Интернет челтәренә һәм шәхси сайтларга керү белән тәэмин ителгән.

2012 ел дәвамында барлык гомуми белем бирү учреждениеләрендә Интернет челтәренә керү тизлеге секундына 5 Мегабиттан артты.

Барлык белем бирү учреждениеләрендә «Электрон мәгариф» мәгълүмат системасы нәтиҗәле эшли.

Мәктәпләрне заманча компьютер техникасы белән тәэмин итү дәрәҗәсе арта (4 укучыга 1 компьютер).

Һөнәри белем бирүне модернизацияләү системаны ресурслар белән тәэмин итү буенча максатчан эш таләп итә.

Белем бирү белән идарә итү органнары эшчәнлегенең төп юнәлешләреннән берсе – белем бирү учреждениеләрен квалификацияле педагогик кадрлар белән тәэмин итү.

Кукмара муниципаль районының мәгариф системасы педагогик кадрлар белән 100% тәэмин ителгән.

2010 елдан Кукмара муниципаль районы педагогик хезмәткәрләренең белем һәм квалификация артуы билгеләп үтелә:

- 98% ы югары белемгә ия;
- 2% хезмәткәр урта һөнәри белемгә ия яки һөнәри белем бирү учреждениеләрендә яки югары һөнәри белем бирү оешмаларында белем ала. Алар – тәрбиячеләр, өлкән вожатыйлар, башлангыч сыйныф укытучылары.

Шулай ук 2010 елдан башлап югары квалификацияле категорияле педагогик хезмәткәрләр саны да артты: Квалификацияле хезмәткәрләрнең гомуми санына карата 20,5% ы югары квалификацияле категориягә ия.

30 яшькә кадәрге югары квалификацияле хезмәткәрләрне Кукмара муниципаль районы мәгариф системасына җәлеп итүгә районның мәгариф учреждениеләренә яшьләрне җәлеп итү буенча региональ грант программаларын гамәлгә ашыру ярдәм итте.

2013 елның 1 августына 6 педагог «Безнең яңа укытучы» республика грант программасында җиңү яулады.

Әлеге программаларны тормышка ашыру Россия Федерациясе Президенты тарафыннан куелган күрсәткечләргә ирешү буенча комплексłы чаралар юнәлешләренең берсе булды:

- 2020 елга югары квалификацияле хезмәткәрләр саны квалификацияле хезмәткәрләрнең 33% ыннан да ким булмаска тиеш;
- 30 яшькә кадәр булган яшь укытучылар саны 2017 елга гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының гомуми санының 25, 5% тәшкил итәчәк.

## 2.2. Программаның максаты һәм бурычлары

Әлеге программада чагылдырылган үзгәртеп коруларның төп стратегик максаты – Кукмара муниципаль районы территориясендә төбәк икътисадының инновацион үсеше, җәмгыять һәм һәр гражданинның өметенә җавап бирә торган сыйфатлы белем алу мөмкинлеген тәэмин итүче белем бирү системасын булдыру.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен Программа тарафыннан түбәндәге бурычларны хәл итү каралган:

1) белем бирүнең эчтәлеген һәм технологияләрен камилләштерү, мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү системасында барлык категория балалар өчен, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен сыйфатлы белем алуда тигез мөмкинлекләр булдыру;

2) Районда өстәмә белем бирү системасының икътисадның инновацион үсеше таләпләренә туры килүен, җәмгыять һәм һәр гражданның өметләрен канәгатьләндерүен тәэмин итә торган шартлар тудыру, тәрбия һәм өстәмә белем бирү системасында заманча сыйфатлы белем бирү һәм балаларны уңай социальләштерү өчен тигез мөмкинлекләр тудыру;

3) белем бирү сыйфатын күтәрү максатларында белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар тарафыннан карарлар кабул итү процессларын ышанычлы һәм актуаль мәгълүмат белән тәэмин итү;

4) сыйфатлы белем алуны тәэмин итә торган инфраструктураны һәм оештыру-икътисадый механизмнарны үстерү.

5) мәктәпкәчә яшьтәге балалары булган Кукмара муниципаль районы территориясендә яшәүче гаиләләргә мәктәпкәчә белем бирүнең уңайлы сыйфатлы хезмәтләрен тәэмин итү һәм ерак территорияләрдә авыл җирендә яшәүче кече мәктәп яшендәге балаларга заманча таләпләргә туры килә торган сыйфатлы белем алуга хокук бирү.

Стратегик максатка ирешү һәм Программаның стратегик бурычларын хәл итү 2015-2017 елларга Кукмара муниципаль районы мәгарифенең төп үсеш юнәлешләрен чагылдыручы кластер принцибы буенча формалаштырылган програма чараларын гамәлгә ашыру хисабына тәэмин итeлә.

## 2.3. Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Программаны тормышка ашыру 2018-2020 елларда бер этапта гамәлгә ашырылачак.

## 2.4. Программаның төп чаралары исемлеге

1 нче таблица

| Чаралар исеме | Чыгымнар категориясе | Башкару вакыты | Чараларны башкаручылар | Җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслау күләме (еллар буенча), мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2018 | 2019 | 2020 | Барлыгы |
| Программаның максаты: Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә төбәк икътисадының инновацион үсеше ихтыяҗларына, җәмгыять һәм һәр гражданинның өметләренә җавап бирә торган сыйфатлы белем алу мөмкинлеген тәэмин итү | | | | **925795,9** | **913651,3** | **861183,6** | **2700630,8** |
| Социаль үсеш институты буларак мәктәп белемен камилләштерү | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның киләчәктә укуга әзерлеген тәэмин итү өчен укучыларның сәләтен үстерү максатында гомуми белем бирү һәм белем бирү | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 60,0 | 65,0 | 70,0 | 195,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| мохитенең эчтәлеген модернизацияләү | | | | | | | |
| Рус телен яклау, саклау һәм тарату, рус телен, әдәбиятын укыту сыйфатын яхшырту | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 40,0 | 45,0 | 50,0 | 135,0 |
| Татар телен туган тел, Татарстан Республикасы дәүләт теле ббуларак яклау, саклау һәм тарату, татар телен, әдәбиятын укыту сыйфатын яхшырту | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 40,0 | 45,0 | 50,0 | 135,0 |
| Укучыларда социаль компетенцияләр, гражданлык установкалары, сәламәт яшәү рәвеше культурасы формалаштыру | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 20,0 | 25,0 | 30,0 | 75,0 |
| Сәламәтлекләре чикләнгән балалар һәм инвалид балалар өчен белем бирүнең сыйфатын һәм һәркем өчен мөмкин булуын арттыру | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 800,0 | 1000,0 | 1200,0 | 3000,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Педагогларны эш сыйфатын күтәрүгә һәм өзлексез һөнәри үсешкә мотивацияләү механизмнарын булдыру | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 100,0 | 150,0 | 200,0 | 450,0 |
| Муниципаль биремнәр нигезендә гомуми белем бирү оешмалары, ведомство буйсынуындагы белем бирү учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе | 122779,4 | 131913,7 | 143351,8 | 398044,9 |
| Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыр, ГТО тапшыру | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 3,0 | 4,0 | 5,0 | 12,0 |
| Муниципаль, региональ һәм бөтенроссия олимпиадалары этапларында җиңүчеләр һәм призерлар өчен чаралар оештыру | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 100,0 | 150,0 | 200,0 | 450,0 |
| Заманча педагогик, инновацион һәм сәламәтләндерү технологияләргә ия булган кадрларның квалификациясен күтәрү | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 30,0 | 40,0 | 50,0 | 120,0 |
| | | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Белем бирү сыйфатын тышкы бәяләү һәм дәүләт – иҗтимагый идарә итү механизмнарын үстерү аша мәгариф системасы эшчәнлеген бәяләүгә белем бирү хезмәтләрен кулланучыларны кертү | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Мәгариф системасы кадрларының квалификация дәрәҗәсен күтәрү, белем бирү сыйфаты мониторингын оештыру, бәяләү процедураларының нәтиҗәләрен анализлау һәм куллану аша район, аерым оешмалар дәрәҗәсендә белем бирү сыйфатын бәяләү культурасын формалаштыру | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 70,0 | 75,0 | 80,0 | 225,0 |
| Шәхси белем бирү казанышлары һәм төрле дәрәҗәләрдә белем бирү | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 0 | 0 | 0 | 0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| сыйфатын мониторинглау системасы турында мәгълүмат җыю һәм анализлау | | | | | | | |
| Белем бирү системасының кадрлар потенциалын камилләштерү | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе | 100,0 | 110,0 | 120,0 | 330,0 |
| Район педагогик конференцияләре, педагоглар белән тантаналы чаралар, ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмаларының бәйрәм һәм юбилей чаралары | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 100,0 | 130,0 | 150,0 | 380,0 |
| Оештыру техникасы, дәреслекләр, укучылар, укытучылар, җитәкчеләр өчен укыту-методик әсбаплар белән тәэмин итү буенча белем бирү оешмасының материаль-техник базасын ныгыту | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 11500,0 | 10700,0 | 11500 | 33700,0 |

## 2.5. Максатка ирешү индикаторлары һәм

**программаны тормышка ашыруның турыдан-туры нәтиҗәләре**

2 нче таблица

| № т/б | Индикатор атамасы/ турыдан-туры нәтиҗә атамасы | Үлчәү берәмлеге | Индикатор күрсәткече/турыдан-туры нәтиҗә | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
| **2.5.1. Максатка ирешү индикаторлары** | | | | | | | |
| 1. | - иң яхшы БДИ нәтиҗәле 10% белем бирү учреждениесендә бердәм дәүләт имтиханнарының уртача баллының (1 предметка исәпләгәндә) иң начар БДИ нәтиҗәле 10% белем бирү учреждениесендәге бердәм дәүләт имтиханнарының уртача баллына (1 предметка исәпләгәндә) карата нисбәте | Нисбәте (отношение) | 1,6 | 1,56 | 1,53 | 1,5 | 1,46 |
| 2. | 5-18 яшьләрдәге халыкның гомуми исәбендә 5-18 яшьләрдәге белем бирүгә җәлеп ителгән халыкның чагыштырма саны | % | 98,6 | 98,8 | 99,0 | 99,1 | 99,2 |
| 3. | Гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның гомуми исәбендә төрле дәрәҗәдәге олимпиадаларда катнашучы гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның чагыштырма саны | % | 70 | 70 | 70 | 70 | 70 |
| 4. | Белем бирү учреждениеләренең гомуми исәбендә инвалидларны һәм үсештә кимчелекләре булмаган затларны бергә укытуны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган универсаль каршылыксыз мохит булдырылган белем бирү учреждениеләрнең өлеше | % | 8,3 | 16,0 | 20 | 20 | 20 |
| 5. | Инвалид-балаларның гомуми исәбендә белем алу хезмәтләрен дистанцион укыту рәвешендә алучы инвалид-балалар өлеше | % | 33 | 33 | 40 | 40 | 40 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Гомуми белем бирү учреждениеләре исәбендә җәмәгатьчелек (ата-аналар, эш бирүчеләр) катнашында коллегиаль идарә органнары булдырылган белем бирү оешмаларының чагыштырма саны | % | 85 | 90 | 100 | 100 | 100 |
| 7. | Гомуми белем бирү учреждениеләре исәбендә үз эшчәнлеге турында рәсми сайтларда белешмәләрнең норматив беркетелгән исемлеген тәэмин итә торган белем бирү оешмаларының чагыштырма саны | % | 70 | 80 | 99 | 100 | 100 |
| 8. | Мәктәпкәчә белем бирү, белем бирү, өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләренең гомуми исәбендә соңгы өч ел эчендә квалификацияне күтәрү яисә һөнәри яктан яңадан әзерлек узган муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, белем бирү учреждениеләре һәм өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләренең чагыштырма саны | % | 71,9 | 78,1 | 84,4 | 87,8 | 90 |
| 9. | Аттестацияләнгән педагогик хезмәткәрләрнең гомуми санында югары квалификацияле категорияле педагогик хезмәткәрләр өлеше | % | 20 | 20,5 | 21 | 21,5 | 22 |
| 10. | Аттестацияләнергә тиешле җитәкче һәм педагогик хезмәткәрләрнең гомуми санында аттестацияләнгән җитәкче һәм педагогик хезмәткәрләр өлеше | % | 75 | 98 | 98 | 98,5 | 98,5 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 11. | Программа кысаларында эшләнгән электрон инструктив-методик ресурсларның гомуми исәбендә Программа кысаларында эшләнгән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә (алга таба – Интернет челтәре) керү мөмкинлеге бирелгән электрон инструктив-методик ресурсларның чагыштырма саны | % | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| 12. | Белем сыйфатын тышкы бәяләү механизмнары гамәлгә ашырыла торган гомуми белем дәрәҗәләре саны | берәмлек ләр | 1 | 1 | 3 | 3 | 3 |
| 13. | Программа нәтиҗәләрен тарату буенча муниципаль дәрәҗәдә үткәрелгән чаралар саны | берәмлек ләр | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |

## 2.6. Хокукый җайга салу чаралары

3 нче таблица

| № т/б | Хокукый акт төре | Хокукый актның төп нигезләмәләре (асылы) | Җаваплы башкаручы һәм бергә башкаручылар | Кабул итүнең көтелгән вакыты |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| 1 нче чара. Районның белем бирү системасы дәрәҗәсе буларак мәктәпкәчә белем бирүне камилләштерү | | | | |
| 1. | Мәгариф идарәсе боерыгы | Мәктәпкәчә белем бирү белән дәүләт-иҗтимагый идарә итүнең вариатив модельләрен кертү турында | Мәгариф идарәләре | Ел саен |
| 2. | Мәгариф идарәсе боерыгы | мәктәпкәчә белем алуның яңа формаларын үстерүне оештыру-методик тәэмин итү турында | Мәгариф идарәсе | Ел саен |
| 2 нче чара. Гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның киләчәктә укуга әзерлеген тәэмин итү өчен укучыларның сәләтен үстерү максатында гомуми белем бирү һәм белем бирү мохитенең эчтәлеген модернизацияләү | | | | |
| 3. | Мәгариф идарәсе боерыгы | Укучыларның республика, Бөтенроссия | Мәгариф идарәсе | Ел саен |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | олимпиадаларының муниципаль этабын оештыру һәм үткәрү турында | | |
| 4. | Мәгариф идарәсе боерыклары | Чаралар оештыру һәм үткәрү турында | Мәгариф идарәсе | Ел саен |
| 3 нче чара. Рус телен, татар телен, дәүләт теле буларак татар телен, туган телләрне яклау, саклау һәм тарату, рус телен, татар телен, дәүләт теле буларак татар телен, туган телләрне, рус, татар әдәбиятын, туган әдәбиятны укыту сыйфатын яхшырту | | | | |
| 5. | Мәгариф идарәсе боерыклары | Чаралар оештыру һәм үткәрү турында | Мәгариф идарәсе | Ел саен |
| 4 нче чара. Укыту һәм тәрбия процессына сәламәтлек саклау технологияләрен кертү, сәламәт яшәү рәвеше турында фикерләүне, сәламәт яшәү культурасы формалаштыру | | | | |
| 6. | Мәгариф идарәсе боерыклары | Чаралар оештыру һәм үткәрү турында | Мәгариф идарәсе | Ел саен |
| 5 нче чара. Сәламәтлекләре чикле балалар һәм инвалид балалар өчен белем бирү сыйфатын күтәрү | | | | |
| 7. | Мәгариф идарәсе боерыклары | Чаралар оештыру һәм үткәрү турында | Мәгариф идарәсе | Ел саен |
| 6 нчы чара. Педагогларны эш сыйфатын күтәрүгә һәм өзлексез һөнәри үсешкә мотивацияләү механизмнарын булдыру | | | | |
| 8. | Мәгариф идарәсе боерыклары | Чаралар оештыру һәм үткәрү турында | Мәгариф идарәсе | Ел саен |
| 7 нче чара. Укучыларны физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү, ГТО нормаларын тапшыру | | | | |
| 9. | Чаралар үткәрү турында мәгариф идарәсе боерыклары | Чаралар үткәрүгә нигезләмәләрне һәм сметаларны раслау | Мәгариф идарәсе, ОО | Ел саен |
| 8 нче чара. Республика, региональ һәм бөтенроссия олимпиадалары этапларында җиңүчеләр һәм призерлар өчен чаралар оештыру. | | | | |
| 10. | Чаралар үткәрү турында боерыклар | Чаралар үткәрүгә нигезләмәләрне һәм сметаларны раслау | Мәгариф идарәсе, ОО ДОД | Ел саен |
| 9 нчы чара Заманча педагогик һәм сәламәтләндерү технологияләренә ия булган кадрларның квалификациясен күтәрү | | | | |
| 11. | Чаралар үткәрү турында мәгариф идарәсе боерыклары | Чаралар үткәрүгә нигезләмәләрне һәм сметаларны раслау | Мәгариф идарәсе, ОО ДОД | Ел саен |
| 10 нчы чара. Мәгариф системасы кадрларының квалификация дәрәҗәсен күтәрү, белем бирү сыйфаты мониторингын оештыру, бәяләү процедураларының нәтиҗәләрен анализлау һәм куллану аша район, аерым оешмалар дәрәҗәсендә белем бирү сыйфатын бәяләү культурасын формалаштыру | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 12. | Мәгариф идарәсе боерыгы | Укучыларның уку казанышларына мониторинг үткәрү турында | Мәгариф идарәсе | Ел саен |
| 11 нче чара Белем бирү системасының кадрлар потенциалын камилләштерү | | | | |
| 13. | ОО боерыклары | Курс әзерлеге планын раслау турында | Районның белем бирү оешмалары | Ел саен |
| 14. | Мәгариф идарәсе боерыгы | Җитәкчеләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге буенча төп күрсәткечләрне актуальләштерү | Мәгариф идарәсе | Ел саен |
| 12 нче чара. Район педагогик конференцияләре, педагоглар белән тантаналы чаралар, ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмаларының бәйрәм һәм юбилей чаралары | | | | |
| 15. | Мәгариф идарәсе боерыгы | Чаралар үткәрү турында | Мәгариф идарәсе | ел саен |
| 13 нче чара Белем бирү оешмасының матди-техник базасын ныгыту | | | | |
| 16. | Мәгариф идарәсе боерыклары | Чаралар планын раслау турында | Мәгариф идарәсе | ел саен |

### 2.7. Программаны тормышка ашыру куркынычларын анализлау

Программаны тормышка ашыру барышында аны тормышка ашыруга тискәре йогынты ясаучы тышкы факторлар барлыкка килергә мөмкин:

- Программаны үтәүгә бүлеп бирелгән бюджет финанславын кыскарту, яңа бюджет параметрларыннан чыгып, аларны хәл итүдән көтелгән нәтиҗәләрне, планлаштырылган чараларны үтәү срокларын киметү күзлегеннән ярдәмче программаның бурычларын яңадан карауга китерәчәк;

- программа чаралары кысаларында каралган аерым эш төрләренә, хезмәт күрсәтүләргә аерым программа чараларына киткән чыгымнарны арттыруга китерәчәк бәяләр арту.

Программаны тормышка ашыруга тышкы факторларның йогынтысын минимальләштерү максатыннан түбәндәге чаралар планлаштырылган:

- Программаны үтәү нәтиҗәләренә һәм финанслау күләмнәренә ел саен төзәтмәләр кертү;

-Программа чараларын мәгълүмати, оештыру-методик һәм эксперт-аналитик яктан тәэмин итү, массакүләм мәгълүмат чараларында Программаны тормышка ашыру процессларын һәм нәтиҗәләрен яктырту;

- кабул ителә торган карарларга экспертиза үткәрү өчен иҗтимагый оешмаларны, һөнәри экспертларны җәлеп итү.

Программаны башкаручылар тарафыннан календарь ел кысаларында, бүлеп бирелә торган финанс чараларын исәпкә алып, программа чаралары буенча максатчан күрсәткечләр һәм чыгымнар тәгаенләнә. Ел йомгаклары буенча үткәрелгән чараларның, финанс ресурсларын тотуның нәтиҗәлелегенә

анализ ясала.

Программа чараларын гамәлгә ашыру буенча хисап гамәлдәге законнар нигезендә тормышка ашырыла.

Программаның муниципаль заказчы-координаторы түбәндәгеләрне башкара:

- төп башкаручылар эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә;

- барлык программа чараларын гамәлгә ашыруның барышы турында мәгълүматларны гомумиләштерә;

- программаны тормышка ашыру мониторингын үткәрә;

- программаны тормышка ашыру белән идарә итә;

- Программа чараларын тормышка ашыру буенча башкарыла торган эшләрне координацияләүне һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

- чираттагы финанс елына тиешле бюджетларны формалаштырганда төрле чыганаклардан Программаны финанслау күләмнәрен ачыклау буенча тәкъдимнәр җибәрә;

- Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына таләп ителгән хисапны тапшыра.

Программаны гамәлгә ашыруны яктырту массакүләм мәгълүмат чаралары һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат ресурслары аша гамәлгә ашырыла.

Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитетының
10.02.2020 елның 142 номерлы
карарына1 нче кушымта

**«2018-2020 елларда Татарстан Республикасы**
**Кукмара муниципаль районында**
**мәктәпкәчә белем бирүне үстерү»**
**муниципаль ярдәмче программасы**

1. Паспорт

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында мәгарифне үстерү» муниципаль максатчан программасы, «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүне үстерү» ярдәмче программасы |
Әлеге ярдәмче программада чагылдырылган үзгәртеп коруларның төп стратегик максаты – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә укучыларны конкурентлыкка сәләтле укытуны һәм чыгарылыш сыйныф укучыларын уңышлы социальләштерүне тәэмин итә торган белем бирү системасын булдыру.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен Программа тарафыннан түбәндәге бурычларны хәл итү каралган:

1. Белем бирү сыйфатын бәяләүнең муниципаль системасын ачыклык, объективлык һәм иҗтимагый-һөнәри катнашу принциплары нигезендә камилләштерү.
2. Педагогларның һөнәри үсеше, мәгариф системасына яшь педагогик һәм идарәче кадрларны җәлеп итү буенча эшне дәвам итү.
3. Туган телне һәм әдәбиятны, РФ дәүләт телен өйрәтүне укыту-методик, ресурслы, мәгълүмат белән тәэмин итүне көчәйтергә, милли, этномәдәни белем һәм тәрбия бирүнең эчтәлеген һәм технологияләрен яңарту.
4. Белем бирү учреждениесендә Федераль дәүләт белем бирү стандартларын нәтиҗәле гамәлгә кертү өчен оптималь шартлар тудыру.
5. Укучыларны инклюзив укыту һәм тәрбияләү, мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен федераль дәүләт белем бирү стандартларын, акылга зәгыйфь балалар өчен федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру өчен оптималь шартлар тудыру.
6. Табигый-математик һәм технологик белем бирүдә заманча сыйфатка ирешүнең гамәли-ориентлашкан модельләрен үстерү.
7. Социаль проектлар буенча максатчан эш нигезендә укучыларны системалы тәрбияләү һәм социальләштерүне тәэмин итү.
8. Сыйфатлы белем алуны тәэмин итә торган инфраструктураны һәм оештыру-икътисадый механизмнарны үстерү.

## 2.3. Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Ярдәмче программаны тормышка ашыру 2018-2020 елларда бер этапта гамәлгә ашырылачак.

## 2.4. Ярдәмче программаның төп чаралары исемлеге

1 нче таблица

| Чаралар исеме | Чыгымнар категориясе | Башкару вакыты | Чараларны башкаручылар | Финанслау күләме (еллар буенча), мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2018 | 2019 | 2020 | Барлыгы |
| Ярдәмче программаның максаты: Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә укучыларны конкурентлыкка сәләтле укытуны һәм чыгарылыш сыйныф | | | | **581450,1** | **609420,5** | **570788,8** | **1761659,4** |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| укучыларын уңышлы социальләштерүне тәэмин итә торган белем бирү системасын формалаштыру | | | | | | | |
| Белем бирү сыйфатын бәяләүнең муниципаль системасын ачыклык, объективлык һәм иҗтимагый-һөнәри катнашу принциплары нигезендә камилләштерергә | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Педагогларның һөнәри үсеше, мәгариф системасына яшь педагогик һәм идарәче кадрларны җәлеп итү буенча эшне дәвам итү | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 60,0 | 65,0 | 70,0 | 195,0 |
| белем җирү оешмаларына гомуми белем бирүнең ФДББСны нәтиҗәле гамәлгә кертү өчен оптималь шартлар тудыру | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 40,0 | 45,0 | 50,0 | 135,0 |
| Укучыларны инклюзив укыту һәм тәрбияләү, мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен федераль дәүләт белем бирү стандартларын, акылга зәгыйфь балалар өчен | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 40,0 | 45,0 | 50,0 | 135,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру өчен оптималь шартлар тудыру | | | | | | | |
| Табигый-математик һәм технологик белем бирүдә заманча сыйфатка ирешүнең гамәли-ориентлашкан модельләрен үстерү | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 20,0 | 25,0 | 30,0 | 75,0 |
| Социаль проектлар буенча максатчан эш нигезендә укучыларны системалы тәрбияләү һәм социальләштерүне тәэмин итү | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 800,0 | 1000,0 | 1200,0 | 3000,0 |
| Социаль проектлар буенча максатчан эш нигезендә укучыларны системалы тәрбияләү һәм социальләштерүне тәэмин итү | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 100,0 | 150,0 | 200,0 | 450,0 |
| Сыйфатлы белем алуны тәэмин итә торган инфраструктураны һәм оештыру-икътисадый | | 2018-2020 | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| механизмнарны үстерү | | | | | | | |
| Муниципаль биремнәр нигезендә гомуми белем бирү оешмалары, ведомство буйсынуындагы белем бирү учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе | 122779,4 | 131913,7 | 143351,8 | 398044,9 |
| Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру , ГТО тапшыру | Башка чыгым нар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 3,0 | 4,0 | 5,0 | 12,0 |
| Муниципаль, региональ һәм бөтенроссия олимпиадалары этапларында җиңүчеләр һәм призерлар өчен чаралар оештыру | Башка чыгым нар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 100,0 | 150,0 | 200,0 | 450,0 |
| Заманча педагогик, инновацион һәм сәламәтләндерү технологияләгә ия булган кадрларның квалификациясен күтәрү | Башка чыгым нар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 30,0 | 40,0 | 50,0 | 120,0 |
| | | | | | | | |
| Белем бирү сыйфатын тышкы бәяләү һәм дәүләт - иҗтимагый идарә итү механизмнары | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 0 | 0 | 0 | 0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| н үстерү аша мәгариф системасы эшчәнлеген бәяләүгә белем бирү хезмәтләрен кулланучыларны кертү | | | | | | | |
| Мәгариф системасы кадрларының квалификация дәрәҗәсен күтәрү, белем бирү сыйфаты мониторингын оештыру, бәяләү процедураларының нәтиҗәләрен анализлау һәм куллану аша район, аерым оешмалар дәрәҗәсендә белем бирү сыйфатын бәяләү культурасын формалаштыру | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 70,0 | 75,0 | 80,0 | 225,0 |
| Шәхси белем бирү казанышлары һәм төрле дәрәҗәләрдә белем бирү сыйфатын мониторинглау системасы турында мәгълүмат җыю һәм анализлау | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 0 | 0 | 0 | 0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Белем бирү системасының кадрлар потенциалын камилләштерү | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе | 100,0 | 110,0 | 120,0 | 330,0 |
| Район педагогик конференцияләре, педагоглар белән тантаналы чаралар, ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмаларының бәйрәм һәм юбилей чаралары | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 100,0 | 130,0 | 150,0 | 380,0 |
| Оештыру техникасы, дәреслекләр, укучылар, укытучылар, җитәкчеләр өчен укыту-методик әсбаплар белән тәэмин итү буенча белем бирү оешмасының материаль-техник базасын ныгыту | Башка чыгымнар | 2018-2020 | Мәгариф идарәсе, ОО | 11500,0 | 10700,0 | 11500 | 3370 0,0 |

**2.5. Максатка ирешү индикаторлары һәм Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләре**

2 нче таблица

| № т/б | Индикатор атамасы/ турыдан-туры нәтиҗә атамасы | Үлчәү берәмлеге | Индикатор күрсәткече/турыдан-туры нәтиҗә | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2018 | 2019 | 2020 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **2.5.1. Максатка ирешү индикаторлары** | | | | | |
| 1. | Агымдагы елда мәктәпкәчә белем алучы 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балалар саны суммасына карата агымдагы елда мәктәпкәчә белем алучы 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балалар саны һәм агымдагы елда мәктәпкәчә белем алу өчен чиратта торучы 3 яшьтән 7 яшькә кадәрге балалар санын 100% ка җиткерергә; | % | 70 | 79 | 100 |
| 2. | Квалификация күтәрүне һәм (яки) һөнәри әзерлекне узган мәгариф хезмәткәрләре (укытучылар, тәрбиячеләр, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләре) өлешен гомуми санда 16,7% ка җиткерергә; | % | 15,2 | 16,2 | 16,7 |
| 3. | Гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның гомуми исәбендә төрле дәрәҗәдәге олимпиадаларда катнашучы гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның чагыштырма саны 70% дәрәҗәсендә саклаunion; | % | 70 | 70 | 70 |
| 4. | Мәктәпкәчә белем бирү программалары белән балаларны колачлау 98 процентка кадәр җиткерергә; | % | 89 | 95 | 98 |
| 5 | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең гомуми исәбендә мәктәпкәчә белем бирү стандартлары таләпләренә туры килә торган программалар буенча белем алучы белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең чагыштырма өлешен 100 процентка кадәр арттырырга; | % | 70 | 79 | 100 |
| 6 | Иң яхшы БДИ нәтиҗәле 10% белем бирү учреждениесендә бердәм дәүләт имтиханнарының уртача баллының (1 предметка исәпләгәндә) иң начар БДИ нәтиҗәле 10% белем бирү учреждениесендәге бердәм дәүләт имтиханнарының уртача баллына (1 предметка исәпләгәндә) карата нисбәте 1,46 га кадәр кимиячәк; | % | 1,53 | 1,5 | 1,46 |
| 7 | Бердәм дәүләт имтиханын тапшырмаган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның гомуми санындагы өлешен 0 процент дәрәҗәсендә саклап калырга; | % | 0 | 0 | 0 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 8 | Яңа федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә укучы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының чагыштырма санын 98% күтәрергә; | % | 87 | 96 | 98 |
| 9 | Гомуми белем бирү оешмаларында балаларны ана телендә укытуны 64 процент дәрәҗәсендә саклап калу; | % | 62 | 62 | 64 |
| 10 | Гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының гомуми исәбенә карата 35 яшькә кадәрге яшь укытучылар санының чагыштырма өлешен 26,5 проценттан да ким булмаган дәрәҗәдә саклап калырга; | % | 25,7 | 25,9 | 26,5 |
| 11. | Педагогик хезмәткәрләрнең гомуми санына карата аттестация узган хезмәткәрләр өлешен 72 процент күләмендә саклап калырга; | % | 72 | 72 | 72 |
| 12. | Аттестацияләнгән педагогик хезмәткәрләрнең гомуми санында югары квалификацияле педагогик хезмәткәрләр өлеше 22% дәрәҗәдә сакланachak; | % | 21,9 | 22 | 22 |
| 13. | Аттестацияләнергә тиешле җитәкчеләр һәм педагогик хезмәткәрләрнең гомуми санында аттестацияләнгән җитәкче һәм педагогик хезмәткәрләр өлеше 98,5% ка кадәр артачак; | % | 93,4 | 95,8 | 98,5 |
| 14. | Белем бирү учреждениеләренең гомуми исәбендә инвалидларны һәм үсештә кимчелекләре булмаган затларны бергә укытуны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган универсаль каршылыксыз мохит булдырылган белем бирү учреждениеләрнең өлеше 20% дәрәҗәсендә саклаnachak; | % | 17,9 | 18 | 20 |
| 15 | Инвалид балаларның гомуми исәбендә белем алу хезмәтләрен дистанцион укыту рәвешендә алучы инвалид балалар өлеше 40% дәрәҗәсендә саклаnachak; | % | 28 | 35 | 40 |
| 16 | Белем бирү оешмаларының гомуми исәбендә җәмәгатьчелек катнашында коллегиаль идарә органнары (ата-аналар, эш бирүчеләр) төзелгән мәгариф оешмаларының чагыштырма саны 100% ка кадәр артачак; | % | 100 | 100 | 100 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 17 | Белем бирү оешмаларының гомуми исәбендә рәсми сайтларда үз эшчәнлекләре турында норматив беркетелгән белешмәләр исемлеген бирүне тәэмин итүче белем бирү оешмаларының агыштырма саны 100% ка кадәр артачак; | % | 100 | 100 | 100 |
| 18 | Программа кысаларында эшләнгән электрон инструктив-методик ресурсларның гомуми исәбендә Программа кысаларында эшләнгән «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә (алга таба – Интернет челтәре) керү мөмкинлеге бирелгән электрон инструктив-методик ресурсларның чагыштырма саны 100% тәшкил итә. | % | 100 | 100 | 100 |

## 2.6. Ярдәмче программаны тормышка ашырудагы куркынычларны анализлау

Программаны тормышка ашыру барышында аны тормышка ашыруга тискәре йогынты ясаучы тышкы факторлар барлыкка килергә мөмкин:

- Ярдәмче программаны үтәүгә бүлеп бирелгән бюджет финанславын кыскарту -, яңа бюджет параметрларыннан чыгып, аларны хәл итүдән көтелгән нәтиҗәләрне, планлаштырылган чараларны үтәү срокларын киметү күзлегеннән ярдәмче программаның бурычларын яңадан карауга китерәчәк;

- программа чаралары кысаларында каралган аерым эш төрләренә, хезмәт күрсәтүләргә аерым программа чараларына киткән чыгымнарны арттыруга китерәчәк бәяләр арту.

Ярдәмче программаны тормышка ашыруга тышкы факторларның йогынтысын минимальләштерү максатыннан түбәндәге чаралар планлаштырылган:

- Ярдәмче программаның үтәлеш нәтиҗәләренә һәм финанслау күләмнәренә ел саен төзәтмәләр кертү;

- Ярдәмче программа чараларын мәгълүмати, оештыру-методик һәм эксперт-аналитик яктан тәэмин итү, массакүләм мәгълүмат чараларында Ярдәмче программаны тормышка ашыру процессларын һәм нәтиҗәләрен яктырту;

- кабул ителә торган карарларга экспертиза үткәрү өчен иҗтимагый оешмаларны, һөнәри экспертларны җәлеп итү.

Ярдәмче программаны календарь ел кысаларында, бүлеп бирелә торган финанс чараларын исәпкә алып, программа чаралары буенча максатчан күрсәткечләр һәм чыгымнар тәгаенләнә. Ел йомгаклары буенча үткәрелгән чараларның, финанс ресурсларын тотуның нәтиҗәлелегенә анализ ясала.

Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру буенча хисап гамәлдәге законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Ярдәмче программаның муниципаль заказчы-координаторы:

- төп башкаручылар эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итә;

- барлык программа чараларын гамәлгә ашыруның барышы турында мәгълүматларны гомумиләштерә;

- Ярдәмче программаны тормышка ашыру мониторингын үткәрә;

- Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру белән агымдагы идарә итүне гамәлгә ашыра;

- Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру буенча башкарыла торган эшләрне координацияләүне һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

- Чираттагы финанс елына тиешле бюджетларны формалаштырганда төрле чыганаклардан Ярдәмче программаны финанслау күләмнәрен ачыклау буенча тәкъдимнәр җибәрә;

- Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына таләп ителгән хисапны тапшыра.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруны яктырту массакүләм мәгълүмат чаралары һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат ресурслары аша гамәлгә ашырыла.

Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитетының
10.02.2020 елның 142 номерлы карарына
3 нче кушымта

**«2018-2020 елларга өстәмә белем бирүне үстерү»**
**муниципаль ярдәмче программасы**

Паспорты

| | |
|---|---|
| Белем бирү учреждениесенең исеме | «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында мәгарифне үстерү» муниципаль максатчан программасы, «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында өстәмә белем бирүне үстерү» ярдәмче программасы |
| Программа эшләү өчен нигез | - Россия Федерациясе Конституциясе;<br>«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон,<br>-Россия Федерациясе Президентының «2012-2017 елларга балалар мәнфәгатьләрендәге гамәлләрнең милли стратегиясе турында» 2012 елның 1 июнендәге 761 номерлы Указы;<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 4 сентябрендәге 1726-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Балаларга өстәмә белем бирүне үстерү концепциясе;<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 29 ноябрендәге 2403-р номерлы боерыгы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт яшьләр сәясәте нигезләре;<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 29 маендагы 996-р номерлы боерыгы белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә Тәрбия үсеше стратегиясе;<br>- «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 28 апрелендәге 71-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- «Өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе» Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 29 августындагы 1008 номерлы боерыгы;<br>- «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;<br>- «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>- «Перспектива» Татарстан Республикасы балаларының һәм яшьләренең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм гамәлгә ашыру Концепциясе турында» Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 9 октябрендәге ПУ-862 номерлы Указы; |

| | |
|---|---|
| | - «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары;<br>- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү концепциясен раслау турында» 2014 елның 16 сентябрендәге 666 номерлы карары;<br>- «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 22 февралендәге 110 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;<br>- «2015 - 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән Стратегик идарә итү» дәүләт программасын раслау турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 3 декабрендәге 943 номерлы карары;<br>- «2015-2025 елларга Татарстан Республикасында белем алучыларны тәрбияләүне үстерү стратегиясен раслау турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 17 июнендәге 443 номерлы карары;<br>- 2014 елның 20 мартындагы ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы N 1465/14 «Күппрофильле өстәмә белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатының модель стандарты»;<br>- тәрбия үсеше, балаларга өстәмә белем бирү мәсьәләләренә кагылышлы өлешендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка хокукый актлары. |
| Эшләүчеләр | «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе |
| Башкаручылар | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе<br>Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының өстәмә белем бирү учреждениеләре, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы белем бирү оешмалары |
| Максат | Өстәмә белем бирү учреждениеләре эшчәнлеген һәм үсешен тәэмин итү, укучылар, аларның ата-аналары, социаль партнерлар һәм гомумән җәмгыять мәнфәгатьләрендә өстәмә белем бирүнең сыйфатын, һәркем өчен мөмкин булуын һәм конкурентлылык сәләтен арттыру өчен, гомуми һәм өстәмә белем бирү системасында укучыларның иҗади сәләтләрен гамәлгә ашыру өчен оештыру, икътисадый һәм методик шартлар тудыру. |
| Бурычлар | - Балаларга өстәмә белем бирүнең эчтәлеген, оештыру формаларын, методларын һәм технологияләрен камилләштерү, инновацион эшчәнлекне, мәгълүмати технологияләрне үстерүгә юнәлдерелгән яңа буын программаларын эшләү.<br>- Балаларның шәхси үсеше, сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, |

| | |
|---|---|
| | һөнәри үзбилгеләнеше һәм иҗади сәләтләрен үстерү өчен кирәкле шартлар тудыру, сәләтле балаларны иртә ачыклау һәм аларгаярдәм итү.<br>- Мәгариф, мәдәният, спорт, сәламәтлек саклау, ата-ана җәмәгатьчелеге, җәмәгать оешмалары, укучыларны гражданлык-патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбияләүдә социаль партнерлык системасын үстерү.<br>- Педагогик һәм җитәкче хезмәткәрләрнең һөнәри компетентлыгын үстерү өчен шартлар камилләштерү.<br>- Яңа финанслау шартларында икътисади идарәнең нәтиҗәле системасын булдыру. Норматив-хокукый базаны камилләштерү. |
| Мөһим максатчан индикаторлар һәм күрсәткечләр | ✓ Өстәмә белем бирүнең сыйфатын күтәрү.<br>✓ Педагогларның һәм укучыларның төрле дәрәҗәдәге конкурсларда катнашуы.<br>✓ Сәләтле һәм талантлы балалар һәм яшьләргә ярдәм итү.<br>✓ Бушлай өстәмә белем бирү хезмәтләре алучы балалар контингентының сакланышы.<br>✓ Учреждениенең кадрлар потенциалын сыйфатлы камилләштерү.<br>✓ Алдынгы педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү һәм аны район педагоглары арасында тарату.<br>✓ Социаль партнерлыкны киңәйтү һәм мәгариф белән идарә итүдә гражданлык җәмгыяте принципларын куллану.<br>✓ Бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | 2018-2020 еллар |
| Максатчан программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Алдан бәяләүләр буенча Программа чараларын гамәлгә ашыру 2020 елга түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- Укучыларның өстәмә белем алу иреген һәм мөмкинлекләрен тәэмин итү;<br>- Өстәмә белем бирүнең нәтиҗәлелегенә һәм сыйфатына ирешү;<br>- Балалар һәм яшүсмерләр сәламәтлегенең сыйфат күрсәткечләрен яхшырту;<br>- Сәләтле балаларны ачыклау, үстерү һәм адреслы ярдәм күрсәтү системасын булдыру;<br>- Төп һәм өстәмә белем бирү интеграциясе нигезендә бердәм белем бирү пространствосын саклау һәм үстерү;<br>- Балаларның төрле эшчәнлек рәвешләре белән мәшгульлеген тәэмин итү һәм, нәтиҗә буларак, колачланган өлкән мәктәп яшендәге балалар санын арттыру, шулай ук балалар берләшмәләре челтәрен үстерү;<br>- Белем бирү системасында яңа мәгълүмати системалар һәм укыту технологияләрен, яңа буын электрон мәгариф ресурсларын кертү |

| | |
|---|---|
| | һәм нәтиҗәле куллану;<br>- Социаль партнерлык дәрәҗәсен күтәрү.<br>- Бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру<br>- Финанслауның бюджеттан тыш чыганакларын җәлеп итү. |
| күләме һәм чыганаклары Финанслауның | 226 943,8 мең сум, шул исәптән еллар буенча:<br>2018 ел – 104351,8 мең сум;<br>2019 ел – 67482,0 мең сум;<br>2020 ел – 55110,0 мең сум; |

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында өстәмә белем бирүне үстерү буенча әлеге Ярдәмче программа «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 22 февралендәге 110 номерлы ТР МК Карары, «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы мәгарифен үстерү» муниципаль программасы, «2018-2020 елларга өстәмә белем бирүне үстерү» муниципаль ярдәмче программасы нигезендә эшләнде.

Ярдәмче программа - белем бирү учреждениесенең билгеле бер чорга бөтен бер система буларак уңай үзгәрешләренең гомуми стратегиясен билгели торган, яңа, тагын да камилрәк сыйфатлы торышын, шулай ук аңа ирешү срокларын һәм ысулларын терки торган документ.

Ярдәмче программа концепцияне, максатларны, бурычларны үз эченә ала һәм үзгәрешләр динамикасында, яңа буын өстәмә белем бирү программаларын эшләү, өйрәнү һәм тикшерү, заманча педагогик технологияләр һәм өстәмә белем бирү методикаларын куллану аша өстәмә белем бирүнең 3 елга эчтәлеген билгели.

Белем бирү программалары аша гамәлгә ашырылган яңа социаль-икътисадый шартларда апробацияләнгән эш юнәлешләрен анализлау балаларга, гаиләгә, җәмгыятькә кирәкле эшчәнлек төрләрен билгеләргә һәм эшчәнлек эчтәлегенә төзәтмәләр кертү өчен ачык яңа мобиль Ярдәмче программа әзерләргә мөмкинлек бирде.

Алдагы тугыз елда (2008-2017 еллар) уңышлы эшләү һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрен үстерү башлангыч педагогик позицияләрнең һәм максатларның дөреслеген, белем бирүне эчтәлегенең адекватлыгын, эшләнгән чараларның һәм алымнарның нәтиҗәлелеген раслады. Программаның концептуаль нигезен өстәмә белем бирү өстенлекләре, мәгариф философиясе, белем бирү эшчәнлегенең максаты һәм бурычлары тәшкил итә.

Учреждениеләр үсешенең методологик нигезе булып, үсеш принцибы белән бергә, зур масштаблы проблемаларны хәл итүгә системалы якын килү тора. Биредә өстәмә белем бирү учреждениеләрендә педагогик процессны оештыру дәрәҗәсен үзгәртүнең кабатланмас процессы күз алдында торкан «үсеш» төшенчәсе үзәк категория булып тора.

Компетентлык-эшчәнлек-компетенция системасы-социумда уңай эшкә сәләтлелек – Ярдәмче программаның төп линиясе шундый. Әлеге стратегик линиядә учреждениеләрнең максаты һәм бурычлары – билгеләнгән проблематиканы үзләштерү һәм үсеш перспективасына карата педагогларның җитди мөнәсәбәтен тәэмин итү, тәрбияләнүчеләр тарафыннан өстәмә белем бирү өстенлекләрен аңлау һәм программалаштырыла торган процессларның төп төшенчәләренә карата җәмәгатьчелек, шул исәптән ата-аналар фикерен формалаштыру.

Программаның төп идеясе булып учреждениеләрдә өстәмә белем бирү практикасында компетентлы якын килү тора. Компетентлыкның табигате эшчәнлеккә нигезләнгән (компетентлык теге яки бу эшчәнлекне тормышка ашыру тәҗрибәсеннән гыйбарәт) буларак, компетентлык эшчәнлектә формалаша һәм камилләштерелә, монннан чыгып, мәгарифтә педагогик процессны системалы рәвештә оештыру белән эшчәнлек парадигмасы барлык учреждениеләр системасы эшендә әйдәп баручы буын итеп кабул ителә.

Үсешне проектлаштыру дигәндә прогрессив үзгәртүне тәэмин итә торган үзгәртеп коруларны гамәлгә ашыру, белем бирү учреждениесен һәм анда белем бирү процессы практикасын камилләштерү күз алдында тотыла.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, социаль-икътисади шартларга бәйсез рәвештә, шәхеснең үз-үзен актив рәвештә тормышка ашыру өчен шартлар тудыруы һәм иҗади эшчәнлек төрләрен сайлау мөмкинлеге тудыруына бәйле рәвештә өстәмә белем бирүгә сорау зур, ул тәрбияләнүчегә иҗади тормыш өчен мөһим булган уңай максат һәм аңа ирешү өчен мөмкинлекләр бирә.

Өстәмә белем бирү хезмәтләрен кулланучылар белем бирүнең сыйфатына, социумның заманча үсешенә туры килә торган, югары таләпләр куя.

Үзгәргән тышкы социаль-икътисадый шартлар объектив рәвештә эчке үзгәрешләрне, белем бирү һәм идарә итү эшчәнлеген камилләштерүне таләп итә

Ярдәмче программа булдырылган тәҗрибәне гомумиләштерү һәм системалаштыру, киләчәктә укыту-тәрбия процессының сыйфаты белән нәтиҗәле идарә итү өчен кирәк. Ул эшчәнлек предметыннан чыгып, учреждениеләрдә белем бирү процессын җайга салучы төп документларны конкретлаштыра, тирәнәйтә һәм киңәйтә.

Концептуаль нигезләмәләр һәм Ярдәмче программаның эчтәлеге ачык проектларда, максатчан программаларда һәм иҗади берләшмәләрнең өстәмә белем бирү программаларында чагылыш таба.

Учреждениеләрнең фәнни-методик базасын үстерү һәм ныгыту, эшчәнлекнең яңа төрләре барлыкка килү, хезмәткәрләрнең һөнәри квалификациясен арттыру, белем бирү эшчәнлегенә яңа методикалар кертү белән Коллективта үсеш Ярдәмче программасына ихтыяҗ барлыкка килде.

Учреждениеләрнең эшчәнлеге, структурасы, методик һәм матди-техник яктан тәэмин ителеше Ярдәмче программа тарафыннан җәмгыять тормышы һәм белем бирү процессы арасындагы аерманы бетерүгә, педагогларның алдынгы эш тәҗрибәсен бөтен төрлелегендә тәрбияләнүчеләр эшчәнлегенә күчерүгә юнәлтеләләр

Белем бирү практикасы, коллектив иҗади эшләр методикасын исәпкә алып, максатчан программа проекты нигезендә тормышка ашырыла. Бу социаль заказны, балалар мәнфәгатьләрен, ата-аналарның сорауларын, хезмәткәрләрнең омтылышын һәм мөмкинлекләрен тулырак исәпкә алырга, кадрлар, матди һәм финанс ресурсларын нәтиҗәлерәк һәм концентрацияле кулланырга, тышкы оешмаларны җәлеп итәргә мөмкинлек бирә.

Ярдәмче программа шулай ук педагогик һәм иҗтимагый мохиттә өстәмә белем бирүнең нәтиҗәле имиджын формалаштыру буенча массакүләм-агарту һәм популярлаштыру эшенең төп юнәлешләрен билгели. Барлык катнашучыларның аңлы рәвештә катнашуы-программада формалаштырылган концептуаль идеяләрне тормышка ашыруның иң нәтиҗәле чараларыннан берсе.

Ярдәмче программаны тормышка ашыруның уңышлы шартлары билгеләнде:

- Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру процессы белән дидактик, методик, идарә итү һәм финанс ягыннан тәэмин итү;
- педагогик коллектив һәм тәрбияләнүчеләр коллективының системалы чараларда һәм спорт чараларында катнашуы;
- традицияләрне саклау, үстерү һәм яңарту, коллектив һәм мәгариф даирәсендә шундый ук структуралар тарафыннан тупланган тәҗрибәне аңлау һәм исәпкә алу;
- соңгы нәтиҗәгә ориентлашу, ирешелгән нәтиҗәләргә системалы анализ ясау;
- эш максатларына, бурычларына һәм формаларына эзлекле төзәтмәләр кертү.

Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитетының
10.02.2020 елның 142 номерлы карарына
4 нче кушымта

**«2018-2020 елларга белем бирү сыйфатын бәяләү системасын үстерү» муниципаль ярдәмче программасы**

1. Паспорт

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында мәгарифне үстерү» муниципаль максатчан программасы, «2018-2020 елларга белем бирү сыйфатын бәяләү системасын үстерү» ярдәмче программасы |
| Программа эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон,<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон,<br>«2020 елга кадәр Россия Федерациясенең озак сроклы социаль-икътисадый үсеше концепциясе» 2008 елның 17 ноябрендәге 1662-р номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте боерыгы,<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгариф системасы мониторингын тормышка ашыру турында» 2013 елның 5 августындагы 662 номерлы карары |
| Программаны эшләүче, программаны тормышка ашыру координаторы | «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе |
| Программаның максатлары | Муниципаль белем бирү системасы белән идарә итүнең төрле дәрәҗәләрендә нигезләнгән идарә карарлары кабул итү өчен мәгариф системасы турында объектив мәгълүмат алу, шулай ук мәгариф өлкәсендә муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның мәгълүматлылык дәрәҗәсен тәэмин итү һәм арттыру |

| | |
|---|---|
| Программаның бурычлары | – муниципаль белем бирү системасының торышы турындагы мәгълүматны җыю, эшкәртү һәм саклауның бердәм системасы механизмын формалаштыру;<br>– мониторинг субъектларының һәм барлык структураларының эшчәнлеген координацияләү;<br>– муниципаль дәрәҗәдә белем бирү системасының торышы һәм үсеше турында дөрес мәгълүмат белән кызыксынучы кулланучыларны тәэмин итү;<br>– муниципаль белем бирү учреждениеләре рейтингын билгеләү һәм аларның эшчәнлеген стимуллаштыру. |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрылыгы |
| Программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе |
| Программаны башкаручылар | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты,<br>Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе,<br>Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары: | |
| **1 нче этап**<br>2018 елның 1, 2 кварталлары | -районның гомуми белем бирү оешмаларында белем бирү сыйфатын өйрәнү;<br>-районда белем бирү сыйфатын билгеләү буенча муниципаль дәрәҗәдәге норматив-хокукый актларны эшләү һәм раслау;<br>- белем бирү сыйфаты мониторингының критерий базасын эшләү һәм раслау;<br>- белем бирү сыйфаты мониторингын үткәрүне технологик тәэмин итү. |
| **2 нче этап**<br>2018 елның 3, 4 кварталлары;<br>2019 ел | Программа чараларын тормышка ашыру.<br>Мәгариф системасы үсешенең барлык юнәлешләре буенча үзгәрешләрне тәмамлау. |
| **3 нче этап**<br>2020 ел | Программа чараларын тормышка ашыруны тәмамлау. Уңай үзгәрешләрнең тотрыклылыгын тәэмин итү механизмнарын формалаштыру. Системаны үстерүнең киләсе чорына максатлар һәм бурычларны билгеләү |

| | |
|---|---|
| Көтелгән нәтиҗәләр | - иң яхшы БДИ нәтиҗәле 10% белем бирү учреждениесендә бердәм дәүләт имтиханнарының уртача баллының (1 предметка исәпләгәндә) иң начар БДИ нәтиҗәле 10% белем бирү учреждениесендәге бердәм дәүләт имтиханнарының уртача баллына (1 предметка исәпләгәндә) карата нисбәте 1,46 га кадәр кимиячәк;<br>- 6,5-18 яшьләрдәге халыкның гомуми исәбендә 6,5-18 яшьләрдәге белем бирүгә җәлеп ителгән халыкның чагыштырма саны 99,2 % ка кадәр артачак;<br>- гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның гомуми исәбендә төрле дәрәҗәдәге олимпиадаларда катнашучы гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның чагыштырма саны 70% дәрәҗәсендә сакланачак;<br>- укучыларның гомуми исәбендә төп заманча таләпләр нигезендә белем алу мөмкинлеге бирелгән муниципаль белем бирү учреждениеләрендә укучыларның чагыштырма саны 81,5% ка кадәр артачак;<br>- белем бирү учреждениеләренең гомуми исәбендә инвалидларны һәм үсештә кимчелекләре булмаган затларны бергә укытуны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган универсаль каршылыксыз мохит булдырылган белем бирү учреждениеләрнең өлеше 20% дәрәҗәсендә сакланачак;<br>- инвалид балаларның гомуми исәбендә белем алу хезмәтләрен дистанцион укыту рәвешендә алучы инвалид-балалар өлеше 40% дәрәҗәсендә сакланачак;<br>- белем бирү оешмаларының гомуми исәбендә җәмәгатьчелек катнашында коллегиаль идарә органнары (ата-аналар, эш бирүчеләр) төзелгән мәгариф оешмаларының чагыштырма саны 100% ка кадәр артачак;<br>- белем бирү оешмаларының гомуми исәбендә рәсми сайтларда үз эшчәнлекләре турында норматив беркетелгән белешмәләр исемлеген бирүне тәэмин итүче белем бирү оешмаларының агыштырма саны 100% ка кадәр артачак;<br>- белем бирү, өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләренең гомуми исәбендә соңгы өч ел эчендә квалификацияне күтәрү яисә һөнәри яктан яңадан әзерлек узган муниципаль белем бирү учреждениеләре һәм өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләренең чагыштырма саны 98% ка кадәр артачак;<br>Аттестацияләнгән педагогик хезмәткәрләрнең гомуми исәбендә югары квалификацияле педагогик хезмәткәрләр өлеше 22% ка кадәр артачак;<br>Аттестацияләнергә тиешле җитәкче һәм педагогик хезмәткәрләрнең гомуми санында аттестацияләнгән җитәкче һәм педагогик хезмәткәрләр өлеше 98,5 % ка кадәр артачак;<br>- Программа кысаларында эшләнгән "Интернет" мәгълүмат |

| | |
|---|---|
| Программаны финанслауның күләме һәм чыганаклары | • Татарстан Республикасы бюджеты;<br>• муниципаль бюджет ;<br>• бюджеттан тыш һәм башка эшчәнлектән акчалар;<br>• ата-аналар взносыннан кергән акча.<br>Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына Программаны финанслауның гомуми күләме<br>27 842,1 мең сум, шул исәптән еллар буенча:<br><br>2018 – 16013,2 мең сум.<br>2019 – 8618,0 мең сум.<br>2020 – 3210,9 мең сум.<br>Искәрмә: Программаны финанслау күләмнәре фаразланган характерга ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш. |
| Программа буенча контроль һәм хисаплылык | Мониторинг алып бару, арадаш контроль, программаны тормышка ашыру барышы турында хисап бирү.<br><br>Программа үтәлешен түбәндәгеләр контрольдә тота: Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе.<br><br>Программаны гамәлгә ашыру кысаларында бюджет акчаларын тотуны контрольдә тоту законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла |